КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 ноябрь г.Казань № 1399

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Капитал салуларга җибәрелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан файдалануның нәтиҗәле булу-булмавын ачыклау буенча инвестиция проектларына тикшерү үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 24 май, 347 нче карары белән расланган Капитал салуларга җибәрелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан файдалануның нәтиҗәле булу-булмавын ачыклау буенча инвестиция проектларына тикшерү үткәрү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Капитал салуларга җибәрелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан файдалануның нәтиҗәле булу-булмавын ачыклау буенча инвестиция проектларына тикшерү үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 ел, 24 май, 347 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 15 август, 669 нчы; 2023 ел, 20 март, 290 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Капитал салуларга җибәрелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан файдалануның нәтиҗәле булу-булмавын ачыклау буенча инвестиция проектларына тикшерү үткәрү кагыйдәләренә, 1 нче кушымтаның 8 пунктындагы «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин